

*Фәүзия Солтан*



# ҮЗӘК ӨЗЕЛГӘН ЧАК

*Шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
С61

**Солтан Фәүзия**

С 61 Үзәк өзелгән чак: Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 79 бит.

Җыентыкта шагыйрәнең уй-моңнарга бай һәм нечкә лиризм белән сугарылган шигырьләре туплап бирелде.

ISBN 5-298-01287-6 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

# I БҮЛЕК

*Туган җирем, аяк басу белән,*
*Мин яшәргә синнән көч алам.*
*Синдә туып, канат чыгардым мин —*
*Меңнәр арасыннан бер балаң.*



## Туган җирем

Туган җирем, аяк басу белән,
Мин яшәргә синнән көч алам.
Синдә туып, канат чыгардым мин —
Меңнәр арасыннан бер балаң.

Канатларым җәеп очып киттем,
Калды болын, кырлар, тугайлар...
Илләр гизеп, сагынып кайтам сиңа,
Синдәй гүзәл җирләр кайда бар?

# Олы Солтаным

Туган авылым Олы Солтан,
Даның илгә таралган.
Синең изге туфрагыңда
Илһамлылар яралган.

Олы да син, Солтан да син,
Якын да син күңелгә.
Кая гына таралсак та,
Кайтабыз туган өйгә.

Тау башында — биек мәчет,
Тау астында — Чәй чишмәң.
Күпме буын шул чишмәнең
Шифалы суын эчкән.

Олы да син, Солтан да син,
Ямьле дә син, авылым.
Изгелеккә өндәп безне
Яңгырый азан моңың.

Сагынып кайтам авылымны,
Көч алам болыннардан.
Солтанымда юл алганнар
Югалмаслар кайда да.

Изге дә син, Солтан да син,
Ямьле дә син, авылым.
Сине сагынган чакларда
Яңгырасын бу җырым.

# Мәдхия

Кирлегәч, Шөгер, Иштирәк,
Тау буенда — Бәкере.
Бу якларга килеп киттең,
Җиргә рәхмәт әйттеңме?

Тауларында учак ягып,
Суларына кердеңме?
Кешеләрнең эшчәннәре
Монда яши — белдеңме?

Риваятьләр сөйләп бирә
Шөгер, Бәкер язмышын.
Пәһлеваннар көрәшен һәм
Саф мәхәббәт сагышын.

Бу якларга килеп китсәң,
Сагындырыр һавасы.
Хиссезләрдә хис уяныр,
Җанга булыр дәвасы.

# Тау иленә

Тау астында — авыл, тау битендә — урман,
Тирә-юньдә — кырлар, болыннар.
Таудан агып чыккан елга бормалана,
Берсен-берсе куа дулкыннар.

Тау башында — болыт, аның зәңгәрлеге
Зәңгәрләтә суның өсләрен.
Офыклардан узып агып китә елга,
Кая илтә тауның серләрен?

Тау буенда — күлләр. Аның ярларында
Зифа булып үсә камышлар.
Тау ягыннан искән җилгә кушылып алар
Серләшәләр төрле тавышка.

Тау өстендә — болыт. Уйнаклыйлар җилләр,
Юлларында юктыр киртәләр.
Биек тауның битен, чал чәчләрен сыйпап,
Сәлам биреп узып китәләр.

Тау артыннан ямьле җәйге аяз таңда,
Кояш калкып сибә нурларын.
Сылу каеннардан төшкән күләгәләр
Колачлыйлар иркен кырларны.

«Тау ягыбыз» диеп, ямьле бу җирләрне
Халык атый сөеп электән.
Тау ягы хакында буыннан буынга
Хикәятләр халкым йөреткән.

Тау астында — авыл. Бүген аның халкы
Бәйрәм итә әрәмәлектә.
Яшәү дәрте бөркеп, Сабан туе гөрли,
Уен-көлке, җырлар һәр җирдә.

Елга суы, урман, күлләр, болыннары,
Тауның көчен безгә тапшыра.
Биек таудан алган бәрәкәтле байлык
Мәңгелек көч бирсен халкыма!

## Онытмам, әнием

Әнием Шиһапова Халисә
Фатыйх кызының якты
истәлегенә багышлыйм

Болыннарда, җырлый-җырлый,
Җиләк җыйган чакларың,
Басуларда, билең бөгеп,
Урак урган чакларың,
Ындырларда, җилгелдереп,
Ашлык әйгән чакларың
Калды әнкәй. Дөньялыктан
Ахирәткә күчтең син.
Күрәчәкләреңне күреп,
Безне калдырып киттең син.
Күргәнең — гомер китабы,
Биргәнең — балаларың.
Үгет-нәсихәт, догаларың
Соңгы сулышыбызгача
Безне озата барыр...

# Газизләрем

Таралышып йоклап ятасыз сез,
Ике улым — ике сизгерем.
Керәм төнлә сезнең бүлмәгезгә, —
Яшәү чыганагым сез минем.

Яннарымнан китеп барсагыз сез,
Ничек түзәр икән йөрәгем?
Күрми торсам сезне сагынам бит,
Күз нурларым, газизкәйләрем.

Төшегезгә ниләр керә икән?
Аргансыздыр инде көнозын.
Олы тормыш юлына соң сезне
Озата алырмынмы ялгызым.

«Сабыйларым!» — чәчегездән сыйпыйм —
Берегезгә инде — унсигез.
Икенчемә — сигез. Яратуым
Икегезгә төшә бертигез.

«Тыныч йокы, газизләрем!» диеп,
Сүндерәмен өстәл утын да —
Басып калам бүлмә уртасында...
Китә алмый торам. Уемда

Сез барасы юллар күренә кебек.
Тик булмасын анда киртәләр.
Ә хәзергә телим, газизләрем,
Тыныч йокы, якты иртәләр!

# *Саумы, әнкәй!*

Кайткан чакта, әнкәй, туган йортка,
Күз яшьләре күрәм күзеңдә.
Сирәк кайтуларга үпкәлисең,
Аңлыйсыңдыр инде үзең дә.

Язмыш шулай, кисәтмичә генә,
Чит җирләрдә мине йөретә.
Әнә кайтам, менә кайтам, диеп,
Йөри-йөри гомер дә үтә.

Синең өчен һаман бала бит без,
Агарса да инде чәчебез.
Сирәк кайтуларга үпкәләмә,
Син бар диеп, җирдә яшибез.

Эшләр уңса, юллар уңса әгәр,
Күтәрелеп китсә күңелләр —
Күзаллыйбыз: әнкәй дога кыла,
Күзләреннән яшьләр түгелә.

Саумы, әнкәй, сагындырдың, диеп,
Кайтабыз бит, зинһар, елама!
Син бар җирдә кояш та яктырак,
Син бар диеп, күңел юана.

## Әнкәем, елама

Әнкәем, елама, тынычлан,
Зарланма, авыр дип, бу тормыш.
Җиңеләйтергә синең хәлеңне
Без бар бит — канат һәм таяныч.

Синең дә, аңлыйбыз, киләдер
Сөелеп, сөенеп яшисең.
Авырлык басса да, иңнәрең
Бирешми яшисең — көчле син.

## Салкын чишмә

Салкын чишмә, чылтырап аккан суың
Каян чыга, кая юл ала?
Әллә соң син җирнең күз яшеме?
Елый микән әллә Җир-Ана?

Нигә елый сагышланып, ярсып?
Тыңла әле күкрәгенә ятып.

Җиребездә яши төрле кеше,
Сулар булып сөю-наз ага.
Әллә бездән юатулар көтеп,
Әрни микән җаның, Җир-Ана?!

Еламасын сагышланып, ярсып,
Юат аны күкрәгенә ятып!

## Җиргә сыенам

Көчле имәннәрнең дә бит
Арган чаклары була.
Зәңгәрлектән туеп, диңгез
Бер болгана, бер тына.

Иректә йөргән болытның
Арып качканы була.
Нинди биек тауларның да
Табаны җирне тоя.

Чәчләр чаларган чакта да,
Әнкәй гел кирәк була.
Уйнавыннан туктагач,
Җитдиләнә һәр бала.

Нинди каты һәм нык булган
Корыч булып корыч сына.
Аргач-талгач, көч җыярга
Сыенамын, Җирем, сиңа.

# Улыма

Юкка-барга вакланма,
Тыйнак бул син, мактанма!
Әйтсәң сүзне — акланма,
Үч-ачуны саклама!
Агымсудай талгын бул,
Искән җилдәй ярсу бул!
Уйланучан, сабыр бул,
Кирәк чакта давыл бул!
Гомереӊ узсын сәламәт,
Озатсын саф мәхәббәт.

***

Суда йөзмим, күктә очмыйм —
Җәяү барасым килә.
Киртәләрне җиңәр көчне
Җирдән аласым килә.

## Күңелемә каты бәрелмәгез!*

*(Җыр)*

Күңелемә каты бәрелмәгез!
Күтәралмыйм авыр сүзләрне.
Авыр сүзләр, ялганнардан,
Алдаулардан, ялалардан
Кайгы-сагыш баса йөзләрне.

Әрәм үтә синең гомерең, диеп,
Ялгыз син, дип, җанга тимәгез.
Ике балам үсеп килә,
Күңелемә шатлык бирә,
Ни шатлыгың бар соң, димәгез!

Ике канат — ике газиз балам,
Мин аларга карап юанам.
Миңа дигән бәхетеңне,
Сөю, сөелү, өметеңне
Син аларга бирче, и Аллам!

Күңелемә каты бәрелмәгез!
Салкын карап үтеп китмәгез.
Зур сынаулар, кайгы-хәсрәт,
Авыр язмыш кичеп яшим —
Яман сүзләр миңа әйтмәгез!

* Р.Алимбеков көе.

## Әни

Мең мәртәбә яндым-көйдем,
Мең мәртәбә өшедем.
Мин бу халәтнең серенә
Хәзер генә төшендем.

Тоймадым мин таң атуын,
Тумады таң ул көнне.
Аһ, ул көнне хәтта кояш
Ник чыкканга үкенде!

Үкендем мин, үртәлдем мин,
Белмәдем кадереңне.
Аңладым җуйгач кадерен
Әнкәем-бәгъремнең.

Әллә инде яшәдем мин,
Әллә соң яшәмәдем —
Белдем кадерең... Тик шулай да
Белмичә яшәгәнмен.

Сабый чакта бит хәтерлим,
Бик еш уйлана идем.
Әнкәйне төштә югалтып,
Елап уяна идем.

Төштә түгел, инде менә
Өндә югалттым аны.
Өнемме бу, төшемме бу —
Томан басты дөньямны.

Яна-туңа, туңа-яна
Кабат-кабат төшендем:
Буласы юк инде бүтән
Әнкәм кебек кешенең.

## Туй бара

Бу йортта бүген туй бара.
Ә урамда — ялгыз яшь ана.
Чәчәктәй яшьлеге тапталган,
Киләчәк томанда югалган.
Сабые, күз нуры ятим калган.

Юлында ялгызы яшь ана...
Күзләреннән әче яшь тама.
Хәтерендә — үз туе. Теләкләр
Теләнгән иде бит анда да.
Бүген ул — ялгызы.
Кулында — сабые.
Ә йортта җыр гөрли. Туй бара.

## Юрау

Бүген төнлә бер төш күрдем:
Суга төштем — батмадым.
Йөзеп чыктым. Яр буенда
Сине генә тапмадым.
Ике улым — ике канат
Каршы алдылар ярда.
Язмыш күпме талкыса да,
Йөзеп чыгып дәрьялардан,
Булырмын текә ярда,
Газиз улларым барда!..

# II БҮЛЕК

*Усалланып, тормыш, сине каргамадым,*
*Башым иеп, мин җиңеллек сорамадым.*
*Башкаларны түбәнсетеп һәм кимсетеп,*
*Югарыга менәм диеп ашкынмадым.*



## Моңлану

Килә китәсе әллә кайларга.
Кыргый тауларга, шомлы тайгага.
Үтәсе килә котып суыгын,
Экваторны һәм чүлләр кызуын.
Менәсе килә күккә — Галәмгә,
Нигә соң канат юк бу адәмдә?
Уйлар, хыяллар гизә дөньяны,
Тик үтәп кенә булмый хыялны.
Шулай хисләнеп гомер дә үтә,
Җан мәңгелеккә калдырып китә.
Күрми дә кала адәм Галәмне,
Бирми дә кала Җиргә сәламне.

***

Очынып, елмаеп йөргәндә
Сүнде дә калды бит күңелем.
Әллә соң хәерсез берәве
Кадады укларын күзенең?

## Баш иелгән

Иелгән башны кылыч кисмәс, диләр.
Иелмәсәң — башсыз калырсың.
Шулай да бит... Күккә баш чөймәсәң,
Дөньяларны ничек танырсың?!

Шулай да бит... Яз утырткан идем,
Чәчәк аткан икән гөлләрем.
Шул гөлләргә үрелгәндә генә,
Баш иелгән икән, белмәдем.

## Каеным

Үсә кыр түрендә ак каен,
Ялгызы иелә җилләрдә.
Өзгәли давыллар ботагын,
Язларда ул кабат яшәрә.

Яшеннәр ялтырый өстендә,
Салкыннар кичерә ялгызы.
Сыенып пары юк янында,
Ялгызга язылган язмышы.

Киләмен, каеным, яныңа,
Син генә тик мине аңлыйсың.
Күңелем — киң кырлар, түрендә
Каендай мин дә бит ялгызым.

## *Фонтан*

Тимер көпшәләрдән, ургып чыгып,
Тирә-юньгә сибелә сулары.
Яктылыкны сибеп бар тарафка
Балкый төрле төстә нурлары.

Онытылып шулай карап торам,
Тимер көпшәләрдән ярсый су.
Җир-Анадан чисталыкны, гүя
Дәваларны безгә ташый су.

Хәтерләтеп чишмә челтерәвен.
Диңгез шавын, ташу тавышын.
Фонтан тора шәһәр уртасында
Җир-Ананың сөйләп сагышын.

# Әйтер идем

Әйтер идем
Көнделдәге уй-хисләрне
Сәйләннәрдәй тезеп-тезеп,
Кайгыларны, көенечләрне
Бөре чагында ук өзеп,
Җаным теләгәнне сөеп,
Аның өчен янып-көеп,
Бер-береңә гомерлеккә
Яшәү өчен дәрт-көч биреп,
Янәшәмдә әткәй-әнкәй
Кайгыртуын, назын тоеп,
Абынганда — таяныргa
Туганнарның барын тоеп,
Җаным көйсә — юатырга
Якын дусның барын тоеп,
Ялкынланып, дөрләп янып,
Тирә-юньгә нурлар сибеп,
Авырлыкка башны ими,
Чит-ятларга серне бирми
Үтсә әгәр гомерләрем —
Яшәдем дип әйтер идем!

***

Ак төс хуҗа бүген дөньяга —
Кар юрган ябынды Җир-Ана.
Йокыга талган ул, ял итә, пакьләнә,
Киләсе язларга дәрт җыя, көч ала.

Ак карга күмелеп оеган —
Агачлар йокыга талганнар.
Җир-Ана куйныннан көч алып,
Уяныр алар да язларда.

Мәрхәмәтсез, салкын кышкы җил,
Сыкратып, башларын идерә.
Тик юкка. Бирешми агачлар,
Җир-Ана аларга көч бирә.

Таралып сибелгән татарлар
Бирешми зилзилә-давылга.
Тамыры, чыгышы — Туган ил,
Туган җир көч бирә халкыма.

## Кайда син, ышаныч?

Ышанычым кими кешеләргә,
Әллә күп ишеттем яманны?
Күзгә карап әйтүчеләр булды,
Әйе, дөрес, диеп ялганны.

Балачакта сизә идем аны,
Дәшми һич тә кала алмадым.
Бар нәрсәне «юк» дип әйтүчегә
Каршы тордым — ярсып еладым.

Шулкадәрле ялган, эчкерлелек
Ничек сыя икән кешегә?
Ышанычым кими кешеләргә,
Таянычым бетә бит җирдә!

Гомеремдә ялганны чыннан мин
Аерырыга кирәген беләм дә.
«Сизгерлеген җуйган бу» димәгез,
Ышанасым килә кешеләргә!

***

Гәүдәң яши кеше арасында,
Сөйләшәсең яки көләсең.
Җанның ятимлеген, ялгызлыгын
Бары үзең генә беләсең.

# *Ялвару*

Йа Ходаем, көч бир миңа
Авырлыкны җиңәргә.
Иңнәремнән алып аны
Таратырга җилләргә.

Йа Ходаем, көч бир миңа
Түбәнлеккә төшмәскә.
Тагын хәсрәт дәрьяларын
Язсын иде кичмәскә.

Йа Ходаем, син бар бит, дип,
Атлыйм һәрбер адымны.
Юанычлар бир син миңа,
Тынычландыр җанымны.

Шушы кыска гомеремдә
Бәхет бирче, Ходаем.
Ышанычым яшәсен, дип,
Башкаемны ораем.

## *Үз телем бит...*

Акыл әйтә: тукта, сабыр ит, ди,
Уйлап әйт, ди, әйтер сүзләрең.
Сүз генә бит. Оча-китә алар.
Тота алмый калам үзләрен.

Уйлагандай гына буламын да,
Әйтеп куям кирәк-кирәкмәс.
Үз телеңә хуҗа булалмасаң,
Тыныч тормыш һич тә эләкмәс.

Әйтсәгез дә миңа кайчакларда
Бар бәлаң бер — шушы телең, дип,
Сизми каласызмы, ә мин сезгә
Тик яхшылык кына телим бит.

Әче чакларым да бик буладыр,
Төрле хәлләр була дөньяда.
Үз телем бит, нишлим, әмма һәрчак
Әйтер сүзем минем өр-яңа.

## Үзгәрдем

Үзгәрдем.
Ничек үзгәрдем.
Дөнья шулай үзгәрттеме?
Үз арбасына утырып,
Көй көйләргә өйрәттеме?

Үзгәрдем.
Ай-һай үзгәрдем!
Җанны кискән күп булдымы?
Бер упкыннан атылып чыгып,
Икенчесенә чумдыммы?
Үз-
гәр-
дем!

## *Халэт*

Бөтерелеп-бөтерелеп, бар нәрсәне дә җимереп,
Кузгалгандай өермәдәй уем минем —
Бер тиенсез эшем, диеп, юкка узган гомерем, дип,
Үз-үземә мин кул селким.

Шикләнүләр, шомланулар тынгы бирми,
Шул чакларда буш савыттай мин шалтырыйм.
Үз-үзеннән гел канәгать кешеләрдән
Көнләшәм һәм... мин аларны күрә алмыйм.

Кинәт шулчак ераклардан тавыш килә,
Ут күргәндәй булам адашкан чагымда.
Сүзләр килә күңелемә. Шигырь туа.
Гүя үлән таш астыннан шытып чыга.

Сөенәмен. Үз җаена төшә дөньям.
Чишмә чылтырый күңелемдә, дәрт уяна.
Назландыра талгын искән җылы җил дә.
Кояш чыга. Уй-хисләрем ялкынлана.

# Ел фасыллары

Язгы тамчы тама...
Сулар ташып ага...
Кайнар хисләр шашып кубармы?
Язда — яшәү көче,
Яшәрә җир йөзе...
Сөю хисе җанга тулырмы?
Аллы-гөлле чәчәк...
Болыннарда — җиләк...
Ямьлелекне йөрәк аңлармы?
Җәйнең назлы җилләре,
Җылы яңгырлары...
Күңелләргә сафлык кунармы?
Сары яфрак — җирдә...
Игеннәр — амбарда...
Көз килгәндә күңел тынармы?
Кышның бусагасы.
Җәйләргә нәтиҗә...
Киләчәктә язлар булырмы?
Тәңкә карлар ява.
Салкынайта һава.
Күңелләргә суык үтмәсме?
Зәмһәрир салкыннар,
Дулаган бураннар
Җаннарны суытып китмәсме?
Фасыллары белән
Еллар узып китә.
Авырлыклар безне җиңмәсен!
Балачак һәм яшьлек
Үтә, картлык җитә.
Гомеребез бушка үтмәсен!

## Мәңгелектә, яшел бу аланда...

Ямьле язда,
Беренче яшел яфракларга елмайганда,
Төпсез күктә эреп беткән
Җиңел канат кошка карап хәйран калганда —
Бер сәер хис, ямансу хис чолгап ала.
«Яшьлек узды» дигән уй бар җанда.

Килер язлар — килә алмам бу аланга.
Тузганаклар, зәңгәр чәчәк үсәр анда.
Шыбырдатып коеп яңгыр явып үтәр,
Салават күпере күктән нурлар сибәр,
Аллы-гөлле күбәләкләр очар анда.

Күпме йөрәкләргә кояш тулыр,
Якты булыр, күңелләрдә бәйрәм булыр.
Уйлап шулай сагышларым таралалар.
Гүя аларны ак болытлар үзенә алалар.

...Йөз елдан соң кабат туып булса иде.
Яшь үләнне, чык тамчысын күрсәң иде,
Кырмысканы атлап үтеп,
Гашыйкларны сискәндерми,
Урманның саф һавасыннан исергәнче йөрсәң иде.

Әйтсәң иде:
— Оялмагыз, пар гашыйклар.
Бу урында мин дә булдым.
Хәзер мин — кош. Күктә бер болыт мин...
Кошкайларым, чит итмәгез.
Сезнең белән мин дә сайрыйм.
Зәңгәр күкне, җирне, суны
Һәм кояшны мактап җырлыйм.

Ялгызлыкны эзлим урман ешлыгында,
Сагышларым шатлыктан да татлы миңа...
Сайрар кошның йөрәк тибешен ишетәм.
Ямьле язда коштай шулай очып үтәм.

Киләчәккә теләк-фатыйха әйтеп китәм:
— Бездән соң да Җир йөзендә
Чәчәк атып җимеш бирсен һәр үсемлек.
Яшелләнсен урман-кырлар,
Агачларда кош сайрасын.
Яшьнәсеннәр яшеннәр гел япь-яшь күктә.
Җир йөзендә җыр җырлансын, һич тынмасын.
Йөз елдан соң
Минем гәүдәм агач булып үсеп чыккач,
Җыр тыңлармын. Тик җырларга кеше булсын,
Җир йөзендә җыр тынмасын!

***

Намуссызлык кичерелми беркемгә дә.
Юл, сәяхәт саф уйлыларны ярата.
Сөенечле хәбәр алып килсә берәү,
Аны көтеп, сукмак түгел, киң юл ята.

***

Җаны ярлының бакчасында яшеллек үсмәс.
Ялкын урынына кура янганда чыга төтен.
Нурлар сибеп, очкын чәчеп яшәмәсәң,
Үзең киткәч, калмас исемең.

***

Кемдер җырлый.
Тынлык җырлый.
Тынлык артында кемдер елый...
Сагышланып, өзгәләнеп вакыт елый...

***

Бездән соң яшәгән буын
Оста булсын, сабыр булсын.
Җиңел куллы һәм үзсүзле,
Чибәр, көчле, уңган булсын!
Җырларыбыз ул буынга юлдаш булсын!..

## Шагыйрь булмас икейөзле

Үз-үзенә файда эзләп,
Кара карганы ак дигән —
Ничек кенә тырышса да,
Җырчы түгел. Булмаган да.

Яхшылыкны «яман» диеп
Уйлый икән әгәр кеше —
Йөрмәсен хәтта якын да
Изге шигърият янында.

Хаклык өчен башны салу
Һәркемгә дә бирелерме?
Герой булып җитмәсә дә,
Шагыйрь булмас икейөзле.

## Күзләрең

Күзләреңдә балкый очкын —
Кем соң үрләткән?
Керфегеңнән тама яшең —
Кем соң рәнҗеткән?

Яңгыр юган болыттай син
Кабат елмайдың.
Күзләреңнең коесына
Нигә моң салдың?

## Сафлану

Яшьни яшен, күкләр күкри, яңгыр ява.
Җир һәм күк бергә кушылган.
Сафлана һава.

Җаннарны да чистартырга
Күк күкрәү һәм яшен кирәк.
Күңелләрдә җыелып күпме юшкын кала.

Хакыйкатьне табу өчен кайчак шундый
халәт кирәк:

Яшьнәсен яшен,
Күкрәсен күк,
Җан сафлана!..

## Кирәкми!

Кирәкми! Берни дә теләмим!
Нәрсә бар, ни булган— шул җитә.
Үзгәртмим. Берни дә үзгәртмим!
Мин дәшмим. Мин сулыйм. Мин яшим.

Ни булса — шул булыр, дип яшим.
Чирләр дә, үлем дә — чынбарлык.
Ни булса — шул булыр. Үзгәртмим.
Җимермим. Төземим — кирәкми.

Яшәү дә, үлем дә — мәңгелек...

## Кемдә — нәрсә

Табигатьтә һәркемнең дә
Үз кирәге — коралы бар:
Бөркеттә ул кәкре томшык, көчле канат.
Үгездә — мөгез, атта — тояк.
Еланда — агу, куянда — аяк.
Балыкта — йөзгеч, арысланда — тырнак.
Көчне биргән ир-атка.
Матурлыкны — хатын-кызга...
Аллалар да чибәрлеккә табынганнар.

## Кара күзлек

Айдай якты йөз.
Күзләр генә ике болыт...
Шундый чибәр йөзләреңә
Нигә кирәк кара күзлек?
Гаеплемен гаепсездән...
Ашыгыч булды соравым...
Шомырт кара күзләреңә
Нигә кирәк кара күзлек?!
Килешсә дә йөзләреңә,
Ни яшерә кара күзлек?

## Дусларга

Дуслар җыелды, шәраб коелды,
Әйтелде теләк — бик матур сүзләр.
Ерак илләрдән китерде сезне
Безнең якларга нинди саф җилләр?
Кая карасаң — нинди нурлы йөз,
Кемне тыңласаң — нинди матур сүз!
Җырлар җырланды, көйләр көйләнде, —
Сезне күрүгә бик канәгать без!

## Туй теләкләре

Язылгандыр алдан язмышыгыз,
Кавыштыгыз бүген икегез.
Җитәкләшеп, күзгә-күз карашып,
Пар канаттай гомер итегез!

Туйлар узып, туннар инде тузгач,
Агаргач та хәтта чәчегез,
Бер-берегезгә бүгенгедәй һаман
Яратам дип кенә дәшегез!

## *Бар да кала*

Кар-боз эри — кояш ала.
Сулар ага — комнар кала.
Агач яна — көлләр кала.
Тирә-юньгә җылы кала.
Коеп яуган яңгыр туктый,
Үтеп киткән болыт кайтмый.
Җәрәхәтне вакыт ала.
Мәңгелеккә эзе кала.
Кайгы китә — чәч агара.
Картлар китә — яшьләр бара...
Кеше китә — бала кала.
Эше кала, төше кала.
Хәтердә истәлек кала.
Вакыт җитеп бар да бетә
Бу дөньяда, бар да кала...

***

Ялгышудан качып булмый икән.
Хата бу, дип уйлап торасың,
Үзең шуны эшләп куясың.

# Җырладым мин җырларымны

Яшерәсем килгән иде җырларыма
Ялгышларым, кайгыларым, сагышларым.
Яңгыратасы килгән иде зәңгәр күктән
Сандугачтай сибеп җиргә шатлыкларым.

Җырладым мин җырларымны
Урмандагы агачларга,
Болыннарга, киң кырларга
Һәм күктәге йолдызларга.

Таралышты җырлар җиргә җилләр белән,
Ашкындылар алар миннән башкаларга.
Яшереп булмый хисләремне. Язмышлар да,
Ялгышлар да җырда бергә уралганнар.

# *Кол түгел*

Башкалардан курыккан кеше,
үзе сизмәсә дә, кол ул.

*Антисфен*

Хисләремдә ирекле мин,
Уйларымда дөнья гизәм.
Күккә менәм, йолдыз булып,
Галәм киңлегендә йөзәм.

Җирне сөям, тормыш сөям.
Кайчакларда тирә-юньгә,
Кешеләргә колак салам...
Түбәнсетеп, мыскыл итеп
Дәшерләр дә
Рәнҗетерләр кебек мине.
Колмы соң мин?
Юк!
Хисләремдә ирекле мин!

## *Ни җитә?*

Юклы-барлы буш сүзләрне
Сөйләшүдән туктар өчен,
Авызыңны йом — шул җитә.
Хәтереңне тыеп кара,
Үткәннәрне онытыр өчен,
Икеләтә көч кирәк...

Иң кыены — дәртне тыю,
Куралмауны җиңә алу.
Ихтыярыңны уч төбенә
Йомарлап, тешне кысып,
Тозлы яшь тамганны сизми
Ирешәсең теләгеңә.

Кеше булганга көчле син.

# Юлларда

Юл тузанына күмелеп,
Юлчы килгән — каршы ал.
Икмәк куй аның алдына,
Кайнар чәй касәгә сал.

Юлга ашкынсын йөрәкләр,
Теләкләр булсын изге.
Юл йөргән кешеләр итеп
Кадерлик һәммәбезне!

Тормыш юллары, дип юкка
Әйтмидер инде халык.
Юлга ашыгып чыкмыйк без,
Һәм чыкмыйк соңга калып!

Юлга ашкына йөрәкләр,
Өметле күзләр — юлда.
Күктә — кояш! Хәерле юл
Тели бит безгә ул да...

Ераклардан юлчы килә,
Юлчы килә — каршы ал!
Ипекәйне куй мичеңә,
Самавырга күмер сал!

## *Уйлар*

Уйлар, уйлар…
Авыр уйлар,
Уйлап сезне арыйммы?
Әллә инде аз булса да
Уйсыз яшәп карыйммы?

Үрләр, үрләр…
Биек үрләр,
Сезгә менеп карыйммы?
Әллә тигез юллар табып,
Ашыкмыйча барыйммы?

Юлларның да авырларын
Узарга туры килер.
Уйларның да авырларын
Уйларга туры килер.

Үрләргә менгән чагында
Егылу да ихтимал.
Юлымны дәвам итәргә
Бирче, Ходам, ихтыяр!

***

Усалланып, тормыш, сине каргамадым,
Башым иеп, мин җиңеллек сорамадым.
Башкаларны түбәнсетеп һәм кимсетеп,
Югарыга менәм диеп ашкынмадым.

## *Нигә алай?*

Нигә алай, нигә болай түгел?
Ник бу тормыш без дигәнчә түгел?
Шул сорауга җавап эзли-эзли
Үтеп бара безгә дигән гомер.

# III БҮЛЕК

*Җавапсыз мәхәббәт булмасын,*
*Һәркем дә очратсын юлдашын.*
*Очкыннан кабынып китсен дә,*
*Сөюең мәңгегә озатсын.*



## *Сиңа тагын ни кирәк?*

Мин сине хуҗам дип саныйм —
Сиңа тагын ни кирәк?
Җырларымны сиңа җырлыйм —
Сиңа тагын ни кирәк?
Яшьлегемне сиңа бирдем —
Сиңа тагын ни кирәк?

Беләсең бит, коллар хисе көчле була —
Өзеләә богау, җимереләә таш диварлар.
Тар ярлардан бәреп чыккан елгалардай
Ямьле, киң һәм якты юл табалар алар.

Ә мин — бер кол. Синең колың.
Син булганда нигә кирәк миңа ирек?
Син әйтсәң, мин юкка чыгам йә дан алам.
Син булмасаң — яшәү бетәр кебек.

Мин бит сиңа тугрылыклы —
Сиңа тагын ни кирәк?
Мин бит сиңа береккәнмен —
Сиңа тагын ни кирәк?

Мәхәббәтнең чагылышы — чуар,
Төрле төстә була,
Миндә ул — тик синең исемең!
Сиңа тагын ни кирәк?!

***

Чәчмикче хисләрне, саклыйкчы,
Югалтмыйк сөюне мәңгегә.
Күзләрем — күзеңдә, кулларым — кулыңда,
Ташлашмыйк, бәгърем, гомергә.

Бирештек вәгъдәләр, вәгъдәләр,
Кавыштык яшьлекнең таңында.
Вәгъдәләр үтәлде, сөюең сүнмәде,
Сүндерә алмады давыллар.

Гомернең көзләре җиткәндә
Карашыйк күзләргә, күзләргә.
Сөюеңә рәхмәт, саф булды мәхәббәт,
Тугрылык көч бирде яшәргә.

## *Сизәсеңме?**

*(Җыр)*

Юлларымда очрадың да —
Йолдыз янды күгемдә.
Күрешер минутлар җитми, —
Үтми көнем бүген дә.

Юлларымда очрадың да —
Үзгәрттең син дөньямны.
Күзләремдә язлар җитте,
Төннәрем булды айлы.

Күңелемдә — күз карашың.
Елмаюың — йөзеңдә.
Нур чәчеп килеп кер әле
Сагышланган көнемдә.

Нурлар сибеп тора йөзең,
Син шуны беләсеңме?
Иңеңә таянып синең
Янәшә барасым килә,
Шуны сизенәсеңме?

* М.Минһаҗев көе.

## *Нишләр идек?*

Сездән башка нишләр идек бу дөньяда?
Янмас идек, көймәс идек, сөймәс идек.
Яшәүнең һич яме юк бит сез булмагач,
Сездән башка утка-суга кермәс идек.

Янган утка керә, диләр, хатын-кызны...
Ут ягучы, дөрләтүче сез бит аны.
Чапкан атны туктатучы — хатын-кыз да,
Чабучы ат сез түгелме, ир-ат халкы?!

Хатын-кызны чәчәк-гөлгә, назга күмеп,
Алиһәм, дип иркәләүче — ир-ат булыр.
Сагыш-хәсрәт, күз яшенә күмүче дә,
Убырлы, дип сүгүче дә — ир-ат булыр.

Сер бирмичә йөргән була хатын-кызлар,
Күңелләрен аңлый белер йөрәк кирәк.
Иңнәренә башны куеп сыенырга,
Юньсезем, дип сагынырга ир-ат кирәк.

# Эзләрмен

Пышылдавың белән нигә
Сүзләремне бүлмәдең?
Бүлмәдең шул. Сине шашып
Сөюемне белмәдең.

Белмәдең шул. Нигә икән
Үзем дә сиздермәдем?

Күзләремә туры карап,
«Бер сүз әйтәм» димәдең.
Димәдең шул. Ул чак ниләр
Уйлавыңны белмәдем.

Белмәдем шул. Инде сине
Гомер буе эзләрмен.

... Эзләрмен шул.

# Сурәт

Мәһабәт ир, сылу хатын анда —
Тотынышкан кулга-кулларын.
Өстәлемдә минем — фоторәсем,
Шул рәсемдә барлык уйларым.

Ир һәм хатын... Пар аккошлар гүя.
Сөю назын сипкән карашлар...
Аккош булып очар кебек алар,
Иңнәрендә әллә канат бар?

Әй очасы килә алар белән,
Әй менәсе килә югары.
Һәм беләсе килә: кая илтә,
Кая таба очар юллары?

Өстәлемдә — сурәт. Шуңа багам,
Таң туугa яңа көн белән.
Бу сурәтнең серен беркем белми —
Аның серен бары мин беләм!

Шул сурәткә карап сизми калдым
Уйларымның ерак киткәнен...
Кеше шулай сизми кала, диләр,
Яшьлегенә кайтып җиткәнен.

Мин сурәткә карыйм, ә ул — миңа
Карый кебек өметләндереп.
Дәртләндереп, ымсындырып бага
Һәм кабатлый: сөю мәңгелек!

***

Көйсез сүзләр җыр булмас,
Гөлсез көннәр яз булмас.
Таш йөрәктә шигырь тумас,
Мәхәббәтсез наз булмас.

***

Көчле син, дип мине ялгышасың,
Күзләремә туры кара әле.
Тормыш йөген бүлешергә сине
Көткәнемне генә аңла әле.

***

Ерактан күрде дә ашкынды каршына.
Тел очында назлы сүзләре...
Битараф карашка сөрлекте — дәшмәде.
Туктамасмы икән йөрәге?

## Исәнме, мәхәббәтем!

Исәнме, мәхәббәтем!
Давыл булып керден күңелгә.
Күңелемдә — син генә.
Башым иелгән минутта,
Күз алдыма серле карап киләсең дә,
Ашкына йөрәк.
Көтмәгәндә очрадың син юлларымда.
Югалма тик.
Яшә әле уйларымда.
Хыялымда бул янымда!

## Вальс

Җилкендереп, дәртләндереп,
Яңгырый җыр — «Миләшләрем».
Очып-очып әйләнәбез,
Онытылмас ял кичләре.

Кулларым — иңеңдә.
Биик без бүген дә.
Кире кайтмас кичләр,
Калыр тик күңелдә.

Күзләр — күздә. Очабыз без,
Көй ягымлы һәм дәртле.
Саубуллашу көне җитә —
Бу кичтә без бәхетле.

Биик әле, әйләниек
«Миләшкәем» көенә.
Сагынырга, сөенергә
Калсын сәбәп күңелдә.

## Җиләк

Иң беренче җиләкләрне
Өздек без икәү бергә.
Балы татлы җиләкләрнең
Иренебездә генә.

Өзеп өлгергән бересен
Учларыңда сузасың.
Берсе — миңа, берсе — сиңа,
Серләр уртак микән соң?

Учларыңда — татлы җиләк,
Көчле куллар балланды.
Җиләк белән сыйладың да
Сүнгән хисләр уянды.

Җиләкләрне таптамадык,
Сайлап кына өздек без.
Хисләр нечкә, өзмәс өчен
Саклык кирәк — сиздек без.

Учларыңа җыеп кына,
Җиләк белән сыйладың.
Киттек. Тауда нидер көтеп,
Җиләклек һәм таш калды.

## *Равил җыры*

Син миңа елмаеп карадың,
Йөрәгемә кинәт ут салдың.
Яшьлегемнең гүзәл чәчәген
Бүләк иттем, ә син алмадың.

Яшьлекнең иң гүзәл чәчәген
Үрелдем алырга — буй җитми.
Зифа каен төсле буй-сының
Күз алдымда тора, һич китми.

Йөзеңдә тулган ай елмая,
Нур балкыта синең күзләрең.
Нишлим соң, һаман син уемда,
Сагыштан саргая йөзләрем.

## *Серлелек*

Нигә соң ялкын күрүгә,
Икебез дә сискәнде?
Ут каршында куллар кулны
Кабат-кабат эзләде.

Утны зурлап һәм дан җырлап,
Нинди йола үтәдек?
Күзләребез коесыннан
Нинди серләр эзләдек?

# Йөрәк сагышы*

Тамагыма төелгән төенне
Йотып карыйм, әмма йоталмыйм.
Тәрәзәңдә ут янганны көтеп
Карап торам — үтеп киталмыйм.

Китеп бардың, хуш, дип, кулың болгап,
Карап калдым моңсу уйлар уйлап.

Саубуллаштык, күзләреңдә — күзем.
Тау лачыным, очтың иреккә.
Чәчләреңнән, йөзләреңнән сыйпап
Туя алмадым — киттең бик иртә.

Басып калдым, хуш, дип, кулым болгап,
Киттең икән нинди уйлар уйлап?

Җылы карашыңны оныта алмам,
Башым идем синең алдыңда.
Шул чакларны әле искә алдым
Менә кабат уйга талдым да.

Карап торам юлга, уйлар уйлап,
Килерсеңме икән кабат урап?

* Ф.Солтан көе.

***

Бу мизгелдә уйларымны
Сиңа әйтәсем килә.
Туры карап күзләреңә,
Серем чишәсем килә.
Хисләремне, җырга салып,
Сиңа көйлисем килә.
Назлап кына иңнәреңнән
Сыйпап сөясем килә.

Бу мизгелдә өзелеп-өзелеп
Сине күрәсем килә.

## Сагыну

Нәрсә булды күңелемә —
Урын таба алмыйм үземә.
Чыгып китәм урамнарга —
Адашыйммы бураннарда?
Әйләнәм дә кабат киләм
Икәүләп йөргән җирләргә.
Эзләрне тик карлар күмгән —
Ямь таба алмыйм, нишләргә?
Ник югалдың бер хәбәрсез,
Өзгәләнә җаным минем.
Уяттың бит, чирттең кылны —
Үзгәрттең, мин сабыр идем.
Хәзер синнән хәбәр көтеп,
Үз-үземә урын тапмыйм.
Киткән юлларыңа карап
Гүя энәгә җеп саплыйм.
Тегәрҗептәй туры юллар
Сине миңа тартса иде.
Бөтенләйгә кайттым, диеп,
Беркөн ишек каксаң иде.

## Телефон

Шалтырачы, телефон,
Яңгыратып бүлмәне.
Ишеттерче сөеклемнән
Миңа дигән сүзләрне.

Шалтырады телефон,
Тик дәшүче ул түгел.
Кайчан ишетермен икән
Тавышыңны, ди күңел.

Шалтырачы, телефон,
Кыскартып араларны.
Кадерлемнең тавышы бит
Йөрәгем дәвалады.

Шалтырады телефон —
Трубкадан ул дәшә.
Аралар да якынайды —
Гүя торабыз янәшә.

## Кирәк

Саклыйм дисәң сөю учагын,
Ялкын өстәп тору кирәк.
Бер назлы сүз әйтсәң әгәр
Сөенепләр тибә йөрәк.

Мәхәббәтне саклап мәңге
Сөюдә бит яну кирәк.
Кайнар хисләр гомер өсти,
Сүрелмә син мәңге, йөрәк!

## Җавапсыз мәхәббәт булмасын

Җавапсыз мәхәббәт булмасын,
Гомерләр заяга узмасын.
Йөзләргә сарылык кунмасын,
Чәчкәләр һичкайчан сулмасын.

Җавапсыз мәхәббәт булмасын,
Һәркем дә очратсын юлдашын.
Очкыннан кабынып китсен дә,
Сөюең мәңгегә озатсын.

## Үлчәү

Сүзне үлчәп сөйләп кенә
Узып булмый гомерләрне.
Кызасың да, очкын оча,
Кала аннан күмерләре.

Күмер кала салкын көлгә,
Утсыз көйри бары йөрәк.
Үлчәүләргә салып хисне
Сүндермичә яшәү кирәк.

## Ак чәчкәләр

Чәчәк бирдең миңа, уйларыннан
Арынсын бу әле, диденме?
Сагыш тулы уйчан күзләремнән
Шатлык тапкан чагың идеме?

Тышта — буран, иңнәремдә — ак шәл.
Ап-ак чәчәк минем кулымда.
Кар-бурандай бөтерелде уйлар,
Аклык-пакьлек сарды җаныма.

Мине сарган сагыш тәлгәшләрен
Сипсен җилләр урман-кырларга.
Ап-ак чәчәк төсле хисләремне
Салам әле моңлы җырларга.

## *Кил әле*

Син килгәч, яктыра бүлмәләр,
Ешрак яныма кил әле.
Сагындырып кына йөрисең,
Рәсемеңдә һаман күзләрем.

Рәсемдәге серле карашың
Җаныма җылылык бирәләр.
Үзәкне өздереп карыйлар,
Әллә соң уемны сизәләр.

Рәсемең урнына үзең син
Янымда тор әле елмаеп.
Ешрак яныма кил әле,
Үтмәсен гомерләр моңаеп.

***

Ямь калмаган яшәвемдә,
Хәзер генә сиздемме?!
Сине югалту булмаган,
Югалтканмын үземне.

## Түзем бул

Таянырга таяныч һәм
Сыенырга нык иң кирәк.
Шул түгелме? Үзе бит, дип,
Ярсып-ярсып тибә йөрәк.

Сабыр итче, ялгышасың,
Хыялыңда яши бит ул.
Күңелеңнең нечкә кылын
Чиртер берәү, тик түзем бул!

## Китмә

Хыянәтне оныт, диеп,
Ялгышлыкка дәшмә мине.
Күктә оча уйларың, дип,
Калдырып та китмә мине.

Утыр әле каршымда син
Күзләремә карап кына.
Колак салма чит-ятларга,
Сүзләремне тыңлап сына.

Синең белән түгел, хисем
Үзем белән көрәшә бит.
Саубуллашам, ә йөрәгем:
Китмә, диеп эндәшә бит.

# Ишетәсеңме?

Ишетәсеңме? Синең белән серләшәм,
Ераклардан сине сагынып эндәшәм.
Тавышым яңгырый галәмне тутырып,
Торсаң иде янәшәмдә утырып.

Күзләремә карыйсың да тынасың,
Серле карап ниләр әйтеп буласың?
Аңладыммы дөрес ул карашыңны?
Күкрәгеңә салдым уйчан башымны.

Яшә, бәгърем, син яши дип, мин яшим,
Ераклардан «сагынам» дип эндәшим.
Җавап сүзе яңгырасын күгемдә:
«Өзелеп сөям, сагынам сине мин дә!»

## Ак кар ява

Күрәсеңме, ак кар ява,
Пакьлек яба җир өстенә.
Ак кар өсләренә басып,
Җитәкләшеп, икәү килә.

Тирә-якны күрми алар,
Болытларда алар гүя.
Кайнар хисләр дулкынында
Сөю килә, яшәү килә.

Юл бирәләр очраганнар —
Күрми алар беркемне дә.
Гүя алар җир йөзендә,
Галәмнәрдә икәү генә.

## Баш имә

Җавапсыз мәхәббәт каршында баш имә!
Ялынма!
Тезләнмә!
Сер бирмә!
Дәрвиштәй ирекле, горур бул!
Күрәмсең, сөю сиңа үзе килә.
Җавапсыз мәхәббәт каршында баш имә!

# *Кемем син?*

Өнемме бу, төшемме?
Эзләп тапкан кешемме?
Кояшыммы, аеммы?
Теләк-омтылышым булып,
Җилдәй чапкан таеммы?

Язымммы син, күземме?
Язмыш дигән көзгемме?
Ничә еллар җәфа чиккән,
Җаным, әллә үзеңме?
Чагылдырдың күземне.

Әйтә алмыйм сүземне,
Өтеп алдың йөземне.
Әллә син ут-ялкынмы?
Әллә язгы ташкынмы?
Әллә син дә минем кебек
Хисләреңнән шаштыңмы?

Кемем син? Үзең әйт.

## *Сүндермичә яшәрмен*

Башны әйләндерде өч көн.
Шаярумы, шашумы?
Ярларына сыя алмый
Кайнар хисләр ташуы.

Бөтерелеп алып менде
Кайнар сөю хисләргә.
Йөрәктәге ярсуларны
Юктыр сүзләр үлчәргә.

Бәхет биргән өч көн өчен
Рәхмәт сиңа, шәһәрем!
Синдә кабынган очкынны
Сүндермичә яшәрмен.

***

Бер-береңә ышаныч булса,
Йөздән нурлар сирпелә.
Бер-береңнән көнләшсәң әгәр,
Телдән агу сибелә.

***

Кайнар хисләр чагыладыр күзләреңдә.
Ямьле дөнья. Якты йөзең. Гүзәл мин дә.
Бәхетле мин. Язмыш сине биргән миңа.
Озаккамы? Ансын бары Хода белә.

***

Аягымда ныклы басып атлаганда,
Күк йөзеннән күзләр йолдыз санаганда,
Давылларны, ташкыннарны җиңәрмен күк
Җир йөзендә син булганга. Син булганда!

***

Кыш салкыны кердеме соң күңелемә?
Көйрим, пыскыйм. Үтеп бара гомер генә.
Кабызырга бер карашың җитәр кебек,
Сүнгән йөрәк кабат дөрләп китәр кебек.

***

Һич кичереп булмый икән хыянәтне,
Уттан алып язмыш суларга салса да.
Сөенеч тә, шатлыклар да баса алмый,
Сызлый күңел. Әрни яра. Йөрәк яна.

***

Әйттең миңа: шигырьләрең бик ямансу,
Күңелләрне күтәрерлек сүзләр кирәк.
Язар өчен шатлык тулы сөю хисен
Күзләремә һаман сине күрү кирәк.

Әйттең миңа: елмаюың гел ямансу,
Гомереңдә көләч булып яшәү кирәк.
Очкын чәчеп, гел елмаеп яшәр өчен,
Янәшәмдә һәрчак синең булу кирәк.

***

Өзгәләнмә, зинһар, йөрәк,
Тәүге сыналуың түгел.
Ян син, ләкин бик сызланма,
Сыкранмачы син дә, күңел.

Булса булсын гомеремнең
Шатлыклы көннәре сирәк.
Явызлыкка бирешмичә
Тип син, йөрәк. Шулай кирәк!

## Онытa алмадым

Кар эрегәндә, җылы назлы җил искәндә,
Йөрәк назга тартылганда,
Язның назын сагынганда —
Күрдем сине.
Ак кардагы эзләреңә дулкынланып
мин карадым.
Шул мизгелдән тынычлыгым җуйдым —
таба алмадым.

Язның болын чәчәгедәй саф көнендә күрдем
сине.
Бер күрүдә бик күптәннән таныш диеп сиздем
сине.
Ак кардагы эзләреңә дулкынланып
мин карадым.
Шул мизгелдән күзләреңнән күземне
ала алмадым.

Юллар буйлап яз йөргәндә, боз киткәндә
күрдем сине.
Көн бер якты, бер караңгы — еладым йә
көлдем инде.
Ак кардагы эзләреңә дулкынланып
мин карадым,
Шул мизгелдән инде сине оныта алмадым.
Оныта алмадым...

# Теләк

Изге, татлы хыялымның
Соңгы чиге булсаң иде.
Синең гомер китабыңның
Төп мәгънәсе булсам иде.
Бар теләгем: тик син генә
Бердәнберем булсаң иде.

Синең һәрчак җырлый торган
Моңлы җырың булсам иде.
Сикәлтәле гомер юлын
Аерылмыйча үтсәк иде.
Шатлыгыңа, бәхетеңә
Мин сәбәпче булсам иде.

Син күтәргән авырлыкны
Икебезгә бүлсәк иде.
Көчле булып, көчсез булып,
Тынгы бирми торсам иде.
Яңгыр җиргә сеңгән кебек,
Йөрәгеңә сеңсәм иде.

Йөрәк тибешең беткәндә,
Синең белән сүнсәм иде.

## *Кирәкме?*

Бу урынга кайсы юлдан
Килдең икән адашмый?
Туктап калдың ниләр уйлап?
Күреп алып дәштең нигә,
Сүзләр таптың ялгышмый?

Таянырга терәкме соң?
Кабул булган теләкме?
Тормыш юллары чатында
Хәл алырга туктаганда,
Очрашулар кирәкме?

## *Ник очраштык икән?*

Үткән гомер... Нигә аерым үткән?
Горурлыклар тилелекме икән?
Ник очраштык икән соңга калып,
Үкенүләрне язмышларга салып?!

Бер язмышка икәү хуҗа түгел.
Әрни күңел... Өзгәләнә күңел...
Йөрәккәем кага арып-талып,
Ник очраштык икән соңга калып?!

## *Кайту*

Каян керден уйларыма,
Фикеремне чуалттың.
Тыныч аккан тормышымда
Ут-өермә уяттың.

Сулар үргә акмый, диләр,
Әллә соң ага микән?
Яшьлек кире кайтмый, диләр,
Хыялда кайта икән.

Әйттең карап күзләремә:
«Тик мине күр төшеңдә».
Туры караган күзләрең
Бүгенгедәй исемдә.

Утлы карашларың белән
Карама миңа бүтән.
Син исемә төшкән саен,
Яшьлеккә кайтып китәм.

***

Язылганны язмышларга
Без барыбер күрәчәк.
Үткәннәр калсын үткәндә,
Якты булсын киләчәк.

## Унбер роза

Өстәлемдә — унбер роза.
Җете кызыл, алсу һәм ак.
Бер касәгә җыелганнар,
Туган көнгә бәхет теләп.
Тик яшь кенә унбер түгел —
Артта калган шактый еллар.

Унбер роза, балачакны
Гүя кире кайтарасыз.
Ялантәпи, бәбкә көтеп
Йөргән чаклар — кайда соң сез?
Сай елгада су кергән чак,
Кайда ул елгыр балачак?

Хәтфә үләндә тәгәрәп,
Шарлавыклар куып чапкан
Озын аяклы какча кызчык,
Ситсы күлмәк, тузган чәч-баш...
Әткәй-әнкәй, җылы кочак,
Калган инде ерак ул чак.

Ромашкалар, зәңгәр чәчәк,
Тукранбашлар үскән болын
Һәр ел саен аллы-гөлле
Чәчәкләргә күмелсә дә,
Анда инде ул кызчык юк.
Еллар башка. Кошлар башка...

Өстәлемдә — унбер роза...
Еллар узган. Уза... Уза...

## *Читтән карап тордың*

Читтә басып карап тордың миңа,
Уйларыңда ниләр — белмәдем.
Дәртле сөю, уртак хисләр белән
Үтеп киткән яшьлек көннәре.

Аланнарда үскән чәчәкләр дә
Тыңлагандыр безнең серләрне.
Сайрар кошлар моңы күмеп киткән
Пышылдаган серле сүзләрне.

Тотынышып бергә әйләндек без
Яшьлек таңыбызның туенда.
Салкын гына карап тордың миңа,
Ниләр булды икән уеңда?

## Гомер китабы

Тормыш юлын синең белән бергә үттек,
Узган гомер юлларыбыз юкка түгел.
Бер-беребезгә җан җылысын биреп кенә,
Язмыш белән бәхәсләшеп үткән гомер.

Биткә кунган җыерчыклар — юкка түгел.
Яшәү яме сирпелә бит йөзебездән.
Салмак кына еллар шулай узып бара,
Язмышларны язу тора үзебездән.

Кайчакларда шул китапны ачып укыйм.
Мәхәббәт нуры бәйләгән икебезне.
Кире кайтса үткән гомер, кабат шулай
Икәү бергә җитәкләшеп китәрбезме?

***

Күпме юллар артта калды,
Аерылганнар елап калды.
Чиктән-чиккә язмыш куды,
Сафлык, пакьлек юлдаш булды.

## Эчтәлек

**I бүлек**
Туган җирем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Олы Солтаным . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Тау иленә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Онытмам, әнием . . . . . . . . . . . . . . 10
Газизләрем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Саумы, әнкәй! . . . . . . . . . . . . . . . 12
Әнкәем, елама . . . . . . . . . . . . . . . 13
Салкын чишмә . . . . . . . . . . . . . . . 13
Җиргә сыенам . . . . . . . . . . . . . . . 14
Улыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Күңелемә каты бәрелмәгез! . . . . . . . . 16
Әни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Туй бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Юрау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18

**II бүлек**
Моңлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Очынып, елмаеп йөргәндә…» . . . . . . . 20
Баш иелгән . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Каеным . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Фонтан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Әйтер идем . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Ак төс хуҗа бүген дөньяга…» . . . . . . . 24
Кайда син, ышаныч? . . . . . . . . . . . . 25
«Гәүдәң яши кеше арасында…» . . . . . . . 25
Ялвару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Үз телем бит… . . . . . . . . . . . . . . . 27
Үзгәрдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Халәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Ел фасыллары . . . . . . . . . . . . . . . 30
Мәңгелектә, яшел бу аланда… . . . . . . 31

«Намуссызлык кичерелми беркемгә дә...» . . 33
«Җаны ярлының бакчасында яшеллек үсмәс...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Кемдер җырлый...» . . . . . . . . . . . . . . 33
«Бездән соң яшәгән буын...» . . . . . . . . 33
Шагыйрь булмас икейөзле . . . . . . . . 33
Күзләрең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Сафлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Кирәкми! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Кемдә — нәрсә . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Кара күзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Дусларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Туй теләкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Бар да кала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
«Ялгышудан качып булмый икән...» . . . . . 38
Җырладым мин җырларымны . . . . . . . . 38
Кол түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Ни җитә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Юлларда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Уйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
«Усалланып, тормыш, сине каргамадым...» . 43
Нигә алай? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
44

**III бүлек**
Сиңа тагын ни кирәк? . . . . . . . . . . .
«Чәчмикче хисләрне, саклыйкчы...» . . . . . 46
Сизәсеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Нишләр идек? . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Эзләрмен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Сурәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
«Көйсез сүзләр җыр булмас...» . . . . . . . 51
«Көчле син, дип мине ялгышасың...» . . . . . 52
«Ерактан күрде дә ашкынды каршына...» . . 52
Исәнме, мәхәббәтем! . . . . . . . . . . . . . 52
Вальс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53

Равил җыры . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Серлелек . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Йөрәк сагышы . . . . . . . . . . . . . . . 55
«Бу мизгелдә уйларымны...» . . . . . . . . 56
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Телефон . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Җавапсыз мәхәббәт булмасын . . . . . . . 60
Үлчәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Ак чәчкәләр . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Кил әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Ямь калмаган яшәвемдә...» . . . . . . . . 62
Түзем бул . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Китмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Ишетәсеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Ак кар ява . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Баш имә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Кемем син? . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Сүндермичә яшәрмен . . . . . . . . . . . . 66
«Бер-береңә ышаныч булса...» . . . . . . . 67
«Кайнар хисләр чагыладыр күзләреңдә...» . 67
«Аягымда ныклы басып атлаганда...» . . . . 67
«Кыш салкыны кердеме соң күңелемә...» . . 68
«Һич кичереп булмый икән хыянәтне...» . . . 68
«Әйттең миңа: шигырьләрең бик ямансу...» 68
«Өзгәләнмә, зинһар, йөрәк...» . . . . . . . 69
Оныта алмадым . . . . . . . . . . . . . . . 69
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Кирәкме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Ник очраштык икән? . . . . . . . . . . . . 72
Кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
«Язылганны язмышларга...» . . . . . . . . 73
Унбер роза . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Читтән карап тордың . . . . . . . . . . . . 74
Гомер китабы . . . . . . . . . . . . . . . 75
«Күпме юллар артта калды...» . . . . . . . 76
76

Литературно-художественное издание

*Фаузия Солтан*

(Назмутдинова Фавзия Сайфутдиновна)

КОГДА В ДУШЕ ПОКОЯ НЕТ

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Т.В.Пашагина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 3.07.2003.
Форматы $70 \times 90^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Петербург» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 2,92+форз. 0,15. Шартлы буяу оттиск 3,80.
Нәшер-хисап табагы 2,22+форз. 0,24.
Тираж 1000. Заказ Я-403.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.